Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Аппак авыл җирлеге Иске Тумба авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

2019 елның 21 ноябре 2№

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2019 елның 11 ноябрендәге 19 номерлы Әлки муниципаль районының «Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге 18 номерлы «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе»карары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлегенең Иске Тумба авылында гражданнар җыенының 2019 елның 21 ноябрендәге 1 номерлы беркетмәсе нигезендә гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

**1.** Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге составына керүче Иске Тумба авылындагы гражданнар җыенын узган дип, ә җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

**2.** «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләр, 80 яшьтән өлкәнрәк затлар һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

-урамнарны яктырту җайланмасы урнаштыру өчен материал сатып алу, яктырту җайланмасы урнаштыру буенча электр монтажы эшләре, хезмәтләр өчен түләү, урамнарны яктырту энергиясе өчен түләүгә–160 сум;

- Аппак авыл җирлеге торак пунктларында суүткәргеч челтәрләрне реконструкцияләү буенча проект-смета, төзелеш эшләрен башкару, су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, скважиналарның санитар зонасын ремонтлау һәм төзү, лаборатор тикшеренүләр өчен түләү-170 сум;

-җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш өю, тигезләү, юллар салу өчен материаллар сатып алу, чабу, кардан чистарту), МТЗ-82 тракторына хезмәт күрсәтү, тракторчыга килешү буенча түләү, тракторга ягулык-майлау материаллары сатып алуга-120 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу, килешү буенча белгечләр эшләгән өчен түләү, тиресне күмү-80 сум;

- паркларны һәм уен мәйданчыкларын төзекләндерү (җирне рәсмиләштерү, җиһазлар урнаштыру һәм карап тоту)-70 сум мәсьәләләре буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Аппак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, биш һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләр, көндезге формада белем алучы студентлар һәм 80 яшькә җиткән затлардан тыш 2020 елда 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
-урамнарны яктырту җайланмасы урнаштыру өчен материал сатып алу, яктырту җайланмасы урнаштыру буенча электр монтажы эшләре, хезмәтләр өчен түләү, урамнарны яктырту энергиясе өчен түләүгә–160 сум;

- Аппак авыл җирлеге торак пунктларында суүткәргеч челтәрләрне реконструкцияләү буенча проект-смета, төзелеш эшләрен башкару, су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, скважиналарның санитар зонасын ремонтлау һәм төзү, лаборатор тикшеренүләр өчен түләү-170 сум;

-җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (грунт, ком, вак таш өю, тигезләү, юллар салу өчен материаллар сатып алу, чабу, кардан чистарту), МТЗ-82 тракторына хезмәт күрсәтү, тракторчыга килешү буенча түләү, тракторга ягулык-майлау материаллары сатып алуга-120 сум;

- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү һәм контейнерлар сатып алу, килешү буенча белгечләр эшләгән өчен түләү, тиресне күмү-80 сум;

- паркларны һәм уен мәйданчыкларын төзекләндерү (җирне рәсмиләштерү, җиһазлар урнаштыру һәм карап тоту)-70 сум.

4.Халык җыены нәтиҗәләрен Аппак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми http://pravo.tatarstan порталында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Әлки муниципаль районы
Аппак авыл җирлеге башлыгы: И. Х. Әбҗәббарова